**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары**

Олы Әтнә авылы 09 март 2021 ел

№ 21

Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендә кабул ителгән 82номерлы «Олы Әтнә авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында " гы карарына үзгәрешләр кертү турында»

"Россия Федерациясе Хөкүмәте актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында" 26.10.2020 ел, № 1742 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, федераль башкарма хакимият органнары актларының мәҗбүри таләпләрен үз эченә алган кайбер актларын һәм аерым нигезләмәләрен юкка чыгару турында, Федераль Дәүләт транспорт күзәтчелеген, федераль дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда тикшереп тору чараларын үткәргәндә аларның үтәлеше бәяләнә торган аерым нигезләмәләрен юкка чыгару турында, шулай ук транспорт чараларын техник карау өлкәсендә мәҗбүри таләпләр" (үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Уставы нигезендә Олы Әтнә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Олы Әтнә авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге турындагы нигезләмәне раслау хакында«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 2 июлендәге 82 номерлы карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

« 3.2.Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының «Автомобиль юлларының техник торышын бәяләү тәртибе турында» 2020 елның 7 августындагы 288 номерлы боерыгы

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: (pravo.tatarstan.ru ) веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы

Олы Әтнә авыл җирлеге башлыгы Г. Г. Хакимов